Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль район Советы өченче чакырылышының
егерменче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль район Советы карары

24 июль, 2018 ел № 155

2018 – 2019 елларга муниципаль милекне хосусыйлаштыруның
фараз планы (программасы) турында

2001 елның 21 декабрендә кабул ителгән 178-ФЗ номерлы “Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында”, 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында” гы Федераль законнары, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының муниципаль милекләрен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмәсе нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль район Советы карар чыгарды:**

1. 2018 – 2019 елларга муниципаль милекне хосусыйлаштыруның фараз планынын (программасын) расларга (кушымта).
2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны “Вперёд” (“Алга”) район гәҗитендә бастырырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталын (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтына (http://pestreci.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми бастырылган көннән көченә керә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов.

Питрәч муниципаль район
Советы карарына кушымта
“24” июль, 2018 ел № 155

2018 – 2019 елларга муниципаль милекне хосусыйлаштыруның
фараз планы (программасы)

1. Гомуми нигезләмә

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2018 – 2019 елларга муниципаль милекне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) 2001 елның 21 декабрендә кабул ителгән 178-ФЗ номерлы “Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында”, 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында” гы Федераль законнары, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставы, 2009 елның 27 апрелендәге (29.12.2017 елда үзгәртелгән № 12) Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының муниципаль милекләрен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль район Советы карары белән расланган.

Хосусыйлаштыру объектларын сатуның башлангыч бәясе «Россия Федерациясенең бәяләү эшчәнлеге турында»1998 елның 29 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә билгеләнгән базар бәясе нигезендә билгеләнә.

Питрәч муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыруның төп бурычы булып муниципаль милекне хосусыйлаштыру хисабына Питрәч муниципаль районы җирле үзидарә органнарының функцияләрен (вәкаләтләрен) һәм бурычларын тәэмин итү өчен файдаланылмый торган һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнмәгән муниципаль милек структурасын оптимальләштерү тора.

Хосусыйлаштыруның төп максатлары булып тора:

- муниципаль милекне хосусыйлаштырудан район бюджетына салым булмаган керемнәр керүне тәэмин итү;
- милек белән идарә итүгә һәм карап тотуга муниципаль район бюджеты чыгымнарын киметү;
- көндәшлекле мохит булдыру;
- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын хосусыйлаштыруда катнашуга җәлеп итү;
- көчемсез милек объектларын тотуга инвестицияләр җәлеп итү.

2018-2019 елларга муниципаль милекне хосусыйлаштыруның прогноз планы (программасы) гамәлдә булу срогы дәвамында аңа Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карарлары нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелә ала.

Ел дәвамында хосусыйлаштырылмаган муниципаль милек объектлары киләсе елга прогноз планына кертелә.

2. Хосусыйлаштыруга тиеш булган муниципаль милек

| № п/п | Урнашкан урыны | Мөлкәтнең исеме | Мәйдан, кв.м. | Хосусыйлаштыруның планлаштырылган вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Белкино авылы | Административ бина, билгеләнүе: торырга яраксыз, кадастр номеры: 16:33:01 01 01:0105:0025 (16:33:010101:105 кадастр номеры белән җир кишәрлеге, җир категориясе: 1612 кв.м. мәйданда административ бина буларак куллану өчен рөхсәт ителгән торак пунктлар җирләре) | 169,8 | 2018 ел. 3-4 кварталы |
| 2 | Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Шәле авылы, Хайруллин ур., 38 йорт | Котельный бинасы | 133,2 | 2018 ел. 3-4 кварталы |